**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«15» нче сентябрь, 2021 ел** **№ 102**

**Биектау муниципаль районы Советының 2019 елның 17 апрелендәге 279 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районында Бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, Биектау муниципаль районы прокурорының «Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәгә» 19.08.2021 02-08-01-2021 номерлы протесты нигезендә, Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2019 елның 17 апрелендәге 279 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында Бюджет процессы турында нигезләмәгә (Советның 07.08.2019 №307, 16.10.2019 №316, 19.03.2020 №363, 27.08.2020 №389 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 9 пунктындагы 6 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе керемнәре чыганаклары исемлегенә һәм бюджет керемнәре чыганаклары реестрына аңарга беркетелгән керемнәр чыганаклары турындагы белешмәләрне кертү өчен тапшыра;»;

2) 6 статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 18 статьяның 2 өлешен:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясенең милли үсеше максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документларына;»;

б) өченче - алтынчы абзацларны тиешле рәвештә дүртенче – җиденче дип санарга;

4) 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Район бюджеты керемнәре район Советына бюджет турындагы карар

проектын кертү көненә гамәлдә булган районның социаль-икътисадый үсеше фаразы, шулай ук күрсәтелгән датага кабул ителгән һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында үз көченә керә торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетдарының салым булмаган керемнәрен билгели торган Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары һәм бюджет законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм район Советының муниципаль хокукый актлары нигезендә фаразлана.

2. Тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм Советның бюджет турында карар проекты район Советына карауга кертелгәннән соң кабул ителгән федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, район Советының муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре чираттагы финанс елында агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр кертелгәндә агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә исәпкә алына.»;

5) 21 статьяның 2 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга

«Кабул ителә торган йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру гамәлдәге йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләрен беренче чиратта планлаштырганда гамәлдәге һәм үтәлмәгән йөкләмәләрне исәпкә алып тормышка ашырыла.»;

6) 23 статьяны:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац белән тулыландырырга

«транспорт салымыннан җирле бюджетлар керемнәре (әгәр Татарстан Республикасы законы белән җирле бюджетларга транспорт салымыннан чигерүләрнең бердәм нормативлары билгеләнгән булса)»;

б) дүртенче - алтынчы абзацларны тиешле рәвештә бишенче – җиденче дип санарга;

7) 28 статьяда:

а) 3 пунктның 8 абзацында «кире кайтарылмый торган керемнәрне» сүзләрен «максатчан билгеләнешкә ия булган кире кайтарылмый торган керемнәрне » сүзләре белән алмаштырырга, «күрсәтелгән бюджетара трансфертларны» сүзләрен «күрсәтелгән чараларны» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа унберенче абзац белән тулыландырырга:

«юридик затларга, бирелүе хисап финанс елында аларның финанс белән тәэмин итү чыганагы мондый субсидияләр булып торган субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле чаралар чикләрендә гамәлгә ашырылган, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре агымдагы финанс елы башына файдаланылмаган калган өлештән артмаган күләмдә субсидияләр бирү өчен агымдагы финанс елы бюджет ассигнованиеләре арттырылган очракта;»;

в) унберенче - ундүртенче абзацларны тиешле рәвештә уникенче – унбишенче дип санарга;

8) 30 статьяның 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Бюджет акчаларын алучы яңа бюджет йөкләмәләрен үзенә җиткерелгән бюджет йөкләмәләренең тиешле лимитлары һәм кабул ителгән, әмма үтәлмәгән бюджет йөкләмәләре арасындагы аермадан артмаган күләмдә ала.»;

9) 33 статьяның 1 пунктындагы 2 абзацны дополнить словами «яисә әлеге орган исеменнән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә эш итәргә вәкаләтле башка зат тарафыннан.» сүзләре белән тулыландырырга;

10) 35 статьяның 2 пунктында «максатчан билгеләнешкә ия субсидияләрне, субвенцияләрне, башка бюджетара трансфертларны бирү максатларында тиешле» сүзләрен «күрсәтелгән чараларны бирүнең максатларына ярашлы» сүзләренә алмаштырырга;

11) 38 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле бюджетны үтәү турында еллык хисапны тышкы тикшерү, әлеге Кодексның таләпләрен үтәп һәм федераль законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, муниципаль район Советының муниципаль хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Җирле бюджетны үтәү турында еллык хисапны тышкы тикшерү, әлеге Кодексның таләпләрен үтәп һәм федераль законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, муниципаль район Советы Татарстан Республикасы контроль-хисап органы белән аңа тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзелгән очракта һәм Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының контроль-хисап органы тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы» нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы                                        Р.Г. Кәлимуллин